ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 18 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы $2^1$ пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш), № 12 (III өлеш); 2005, № 2; 2006, № 2 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 5 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш); 2013, № 1, № 5; 2014, № 4, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 4, № 12 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 38 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш), № 96 (I өлеш); 2023, № 92 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле (шул исәптән, акылга зәгыйфьлекнең төрле рәвешләре булган) ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар көндезге бүлектә бер мәртәбә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән эшчеләрне һәм хезмәткәрләрне яңадан әзерләү программалары буенча белем алу хокукына ия булалар. Әлеге затларга көндезге бүлектә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән эшчеләрне һәм хезмәткәрләрне яңадан әзерләү программалары буенча белем алуның бөтен чоры дәвамында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән күләмнәрдә һәм тәртиптә уку әдәбияты һәм язу әсбаплары сатып алуга еллык пособие һәм айлык пособие түләнә.».

**2 статья**

Әлеге Закон 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 23 декабрь
№ 136-ТРЗ